**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 15 апрелендәге 1167 номерлы карары**

## Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 3 июлендәге 3854 номерлы «Казан шәһәре муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында

Казан шәһәре муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне җайга сала торган муниципаль норматив хокукый актларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының гамәлдә булган 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарына (2018 елның 31 октябрендәге 965 номерлы, 2018 елның 29 декабрендәге 1262 номерлы, 2019 елның 6 маендагы 380 номерлы, 2019 елның 11 июлендәге 565 номерлы, 2019 елның 28 августындагы 714 номерлы, 2019 елның 2 ноябрендәге 1008 номерлы, 2019 елның 30 декабрендәге 1278 номерлы, 2020 елның 16 апрелендәге 294 номерлы, 2020 елның 21 маендагы 413 номерлы, 2020 елның 1 сентябрендәге 772 номерлы, 2020 елның 23 октябрендәге 954 номерлы, 2021 елның 26 июлендәге 645 номерлы, 2021 елның 6 сентябрендәге 821 номерлы, 2021 елның 29 октябрендәге 1021 номерлы, 2021 елның 30 октябрендәге 1030 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 566 номерлы, 2022 елның 22 сентябрендәге 1027 номерлы, 2023 елның 11 мартындагы 232 номерлы, 2023 елның 19 августындагы 989 номерлы, 2023 елның 16 октябрендәге 1312 номерлы, 2023 елның 31 октябрендәге 1377 номерлы, 2023 елның 7 ноябрендәге 1431 номерлы, 2024 елның 11 маендагы 318 номерлы, 2024 елның 24 июнендәге 454 номерлы, 2024 елның 25 сентябрендәге 830 номерлы, 2024 елның 14 ноябрендәге 1003 номерлы, 2024 елның 30 декабрендәге 1273 номерлы, 2025 елның 12 мартындагы 149 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып) туры китерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 3 июлендәге 3854 номерлы «Казан шәһәре муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 19 мартындагы 869 номерлы, 2019 елның 29 октябрендәге 3921 номерлы, 2022 елның 28 февралендәге 563 номерлы, 2022 елның 6 апрелендәге 962 номерлы, 2023 елның 18 гыйнварындагы 110, 111 номерлы, 2024 елның 9 февралендәге 453 номерлы, 2024 елның 16 сентябрендәге 3906 номерлы, 2024 елның 22 ноябрендәге 4770 номерлы, 2025 елның 27 февралендәге 475 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Казан шәһәренең гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә, 16 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

**«16 нчы таблица**

**Җитәкчеләрнең хезмәте өчен түләү буенча төркем, гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең төп окладлары һәм башкара торган эшләренең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерында түләүләр күләме**

| Җитәкченең хезмәте өчен түләү буенча төркем | Күләм күрсәткече зурлыгы (уку елы башына укучылар, тәрбияләнүчеләр саны), кеше* | Төп оклад, сум | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерында түләүләр, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 1-15 | 37000 | 8000 |
| 2 | 16-50 | 39000 | 8000 |
| 3 | 51-100 | 41000 | 9000 |
| 4 | 101-200 | 42000 | 10000 |
| 5 | 201-400 | 43000 | 11000 |
| 6 | 401-600 | 44000 | 12000 |
| 7 | 601-800 | 45000 | 12000 |
| 8 | 801-1000 | 48000 | 12000 |
| 9 | 1001-1200 | 49000 | 13000 |
| 10 | 1201-1400 | 50000 | 14000 |
| 11 | 1401-1800 | 50000 | 17000 |
| 12 | 1801 һәм аннан күбрәк | 51000 | 20000 |

*Гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда яшәүче укучылар контингенты 2 коэффициенты белән исәпкә алына.

Гомуми белем бирү оешмаларының мәктәпкәчә төркемнәрендә тәрбияләнүчеләр контингенты 1,5 коэффициенты белән исәпкә алына.

Мәктәпара уку-укыту комбинатларында укучылар контингенты 0,5 коэффициенты белән исәпкә алына».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**